*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 40**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен-теш тартык авазларын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [б], [п], [м], [w]
   ә) [в], [ф]
   б) [к], [г]
   в) [к], [ғ], [н], [һ]

2. Ябык иҗекләрдән генә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) бакчалар
   ә) мәктәбебез
   б) дәфтәрләрнең
   в) укучыдан

3. ***Куе*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) аз
   ә) сыек
   б) тирән
   в) сай

4. Искергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ашханә
   ә) флешмоб
   б) китап
   в) мәктүп

5. Кушылып языла торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) каз(үрдәк)
   ә) җир(җиләге)
   б) юл(барыс)
   в) исле(сабын)

6. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) зәңгәр
   ә) зәп-зәңгәр

б) зәңгәррәк
в) зәңгәрсу

7. Үткән заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) шатланды
ә) сөйләр
б) бел
в) утыралар

8. Боеру җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Балалар мәктәп бакчасында эшлиләр.
ә) Кыярлар өлгергән.
б) Агачларның яфраклары нинди төстә?
в) Кошларның сайрауларын тыңлагыз.

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Ялгызлык исемнәре ___________ хәрефтән языла. Авазларның әйтелешен язуда күрсәтү ___________ дип атала. Сүзлекләр төзү турындагы фән ___________ дип атала. Парлы сүзләр һәрвакыт ___________ языла. ___________ фигыльләр эш кушуны белдерә. Җөмләдә бер үк сорауга җавап биргән, бер үк сүзне ачыклаган сүзләр ___________ кисәкләр дип атала.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

*дым* – ___________ *скорость* – ___________
*паук* – ___________ *экзамен* – ___________

2. “Минем гаиләм” дигән темага 8 җөмләдән торган инша языгыз. **(14 балл)**